| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**28.12.2021** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3396** |

2022 - 2024 елларга Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында

2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге«Законны саклаучы кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 990 номерлы карары , Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 - 2024 елларга Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын кушымтада бирелгән тәртиптә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы оставында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http:zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Расланган
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
28.12.2021 ел. №3396

**2022 - 2024 елларга Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы**

**ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | 2022 - 2024 елларга Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы |
| **Программаны эшләүнең хокукый нигезләре** | 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021елның 25 июнендәге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Законны саклаучы кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасының контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 990 номерлы карары |
| **Программаны эшләүче** | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаның максатлары** | - контрольдә торучы барлык затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәүне стимуллаштыру;<br>- закон белән саклана торган кыйммәтләргә һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга зыян(зарар) китерергә мөмкин булган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү;<br>- мәҗбүри таләпләрне контрольдә торучы затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында хәбәрдарлыкны арттыру |
| **Программаның бурычлары** | - закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне , муниципаль актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычын |

| | |
|---|---|
| | бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү;<br>- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне , муниципаль актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү;<br>- профилактик чараларның төрләренең, рәвешләренең һәм интенсивлыгының конкрет контроль субъектларының (объектларның) үзенчәлекләреннән бәйлелеген билгеләү һәм бәяләүһәм әлеге факторларны исәпкә алып, профилактик чаралар үткәрү;<br>- профилактик эш оештыру өчен кирәкле булган статистик мәгълүматларның төрләре исемлеген билгеләү һәм аларны җыю;<br>- контрольдә торучы субъектларга, шул исәптән заманча мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып, консультация бирү системасын булдыру;<br>- җайга салына торган өлкә иминлегенең ачыкланган проблемаларына һәм профилактика эшенең агымдагы торышына бәйле рәвештә башка бурычлар. |
| **Программаны гамәлгә ашыру срогы һәм этаплары** | Программа өч елга исәпләнгән һәм 2022-2024 елларда (2022 елда – кыска вакытлы чор, 2023-2024 елларда план чорында) тормышка ашырылачак. |
| **Финанслау чыганаклары** | Зеленодольск муниципаль районы бюджеты. Программаны тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү муниципаль контрольне гамәлгә ашыру чараларын финанслау кысаларында гамәлгә ашырыла. |
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре** | - закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян килү куркынычын киметү;<br>- законга буйсынучан контрольдә торучы субъектларның өлешен арттыру -контроль органның профилактик чаралар системасын үстерү;<br>- профилактиканың төрле ысулларын кертү;<br>- контроль орган эчендә профилактик эш технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү;<br>- контрольдә торучы субъектларның нәтиҗәле, законга буйсынучан тәртип үрнәкләрен эшләү;<br>- контроль органның вазыйфаи затларының квалификацияле профилактик эшен тәэмин итү;<br>- контроль орган эшчәнлегенең ачыклыгын арттыру;<br>-контрольдә торучы субъектларга административ йөкләнешне киметү;<br>- контрольдә торучы субъектларның хокукый грамоталылыгы дәрәҗәсен күтәрү;<br>- контрольдә торучы субъектлар тарафыннан контроль предметын аңлауның бертөрлелеген тәэмин итү;<br>- контрольдә торучы субъектларның намуслы тәртибен мотивацияләү;<br>- башка. |

| Программа структурасы | 1 нче бүлек. Контрольдә торучы өлкәнең агымдагы торышын анализлау һәм бәяләү.<br>2 нче бүлек. Профилактика программасын гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары.<br>3 нче бүлек. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү сроклары (периодик рәвештә).<br>4нчебүлек. Профилактика программасының эффективтивлыгы һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре. |
|---|---|

**1 нче бүлек. Контрольдә торучы өлкәнең агымдагы торышын анализлау һәм бәяләү.**

1.1. Җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешма йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль контроль предметы булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру барышында бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетика нәтиҗәлелеген тәэмин итү өчен кирәкле һәм җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән, 2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» 190-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен һәм аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларны, шул исәптән мондый гамәлгә ашырыла торган чараларның җылылык белән тәэмин итү схемасына туры килүе тора.

1.2. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләрен үтәүне, профилактик чараларны оештыруны һәм уздыруга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата контроль чаралар "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.3. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләрен үтәүнең муниципаль контроль объектлары булып түбәндәгеләр тора:

а) 2010 елның 27 июлендәге “Җылылык белән тәэмин итү турында” 190-ФЗ номерлы Федераль законның 23.7 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиешле йөкләмәләрне үтәү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма (алга таба шулай ук - контрольдә тотыла торган зат) эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы), аның нигезендә бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы җылылык белән тәэмин итү схемасында күрсәтелгән исемлек һәм сроклар нигезендә җылылык белән тәэмин итү системасының үсеше, ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чараларын гамәлгә ашырырга бурычлы;

б) 2010 елның 27 июлендәге “Җылылык белән тәэмин итү турында” 190-ФЗ номерлы Федераль законның 23.7 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма, шул исәптән продукция (товарлар), эш һәм хезмәт нәтиҗәләре;

в) биналар, бүлмәләр, корылмалар, линия объектлары, шул исәптән су, җир һәм урман кишәрлекләрен, җиһазларны, предметларны, материалларны, транспорт чараларын, табигать мохите компонентларын, табигый һәм табигый-антропоген объектларны, бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасына ия булган һәм (яисә) файдаланган башка объектлар, табигый мохит компонентлары, бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасына ия булмаган һәм (яисә) файдаланмаган табигать һәм табигый-антропоген объектлар (алга таба - җитештерү объектлары), аларга 2010

елның 23 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела.

1.4. Башкарма комитет тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешен җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау һәм актуальләштерү юлы белән бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешен муниципаль контроль объектларын исәпкә алу тәэмин ителә.

## 2 нче бүлек. Профилактика эшен үткәрүнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау - бу түбәндәге төп максатларга ирешүгә юнәлдерелгән оештыру, мәгълүмати, хокукый һәм башка характердагы чараларны комплекслы гамәлгә ашыру буенча системалы оештырылган эшчәнлек:

- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын булдырмау;
- Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешенә контроль өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны (мәҗбүри таләпләрне бозуларны, муниципаль актларда билгеләнгән таләпләрне )кисәтү ;
- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау инфраструктурасын булдыру .

2.2. Профилактик чаралар үткәрү түбәндәге бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне , муниципаль актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычын бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү;
- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне , муниципаль актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү;
- профилактик чараларның төрләренең, рәвешләренең һәм интенсивлыгының конкрет контроль субъектларының (объектларның) үзенчәлекләреннән бәйлелеген билгеләү һәм бәяләүһәм әлеге факторларны исәпкә алып, профилактик чаралар үткәрү;
- профилактик эш оештыру өчен кирәкле булган статистик мәгълүматларның төрләре исемлеген билгеләү һәм аларны җыю;
- контроль органнарның кадрлар составы квалификациясен күтәрү;
- контрольдә торучы субъектларга, шул исәптән заманча мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып, консультация бирү системасын булдыру;
- җайга салына торган өлкә иминлегенең ачыкланган проблемаларына һәм профилактика эшенең агымдагы торышына бәйле рәвештә башка бурычлар.

## 3 нче бүлек. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү сроклары (периодик рәвештә).

Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләре үтәлешенә муниципаль контроль Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырганда түбәндәге профилактик

чаралар төрләре үткәрелергә мөмкин:

1) мәгълүмат җиткерү;
2) хокук куллану практикасын гомумиләштерү;
3) кисәтүләр игълан итү;
4) консультация бирү;
5) профилактик визит.

**Мәгълүмат җиткерү** мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча Башкарма комитет тарафыннан "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) (алга таба - районның рәсми сайты) контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә (махсус бүлеккә керү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтының төп (төп) битендә) массакүләм мәгълүмат чараларында, дәүләт мәгълүмат системаларында контрольдә тотыла торган затның шәхси кабинетлары аша (алар булганда) һәм башка рәвешләрдә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет шулай ук Зеленодольск шәһәре халкына контроль объектларына карата куелган мәҗбүри таләпләр турында гражданнарның җыелышларында һәм конференцияләрендә хәбәр итәргә хокуклы.

**Хокук куллану практикасын гомумиләштерү** Башкарма комитетның вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре, шулай ук кергән мөрәҗәгатьләрне җыю һәм анализлау юлы белән гамәлгә ашырыла. Контроль орган хокук куллану практикасын гомумиләштерү йомгаклары буенча елга кимендә 1 тапкыр гавами фикер алышулар уза торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерләнә.

**Кисәтүне игълан итү.** Контроль органда мәҗбүри таләпләрне бозуның әзерләнүләре яисә мәҗбүри таләпләрне бозуның билгеләре турында белешмәләр булган очракта , шулай ук мәҗбүри таләпләрне турыдан-туры бозу турында белешмәләр булганда, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә торучы торган затка мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү чараларын күрергә тәкъдим итә.

Контрольдә торучы затларга консультация бирү муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итүдә йә профилактик чаралар, контроль чаралар үткәрү барышында гамәлгә ашырыла һәм 15 минуттан артмаска тиеш.

**Профилактик визит:**

1) Профилактик визит вазыйфаи зат тарафыннан контрольдә торучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча профилактик әңгәмә рәвешендә йә видеоконференция-элемтә аша үткәрелә.

2) Вазыйфаи зат профилактик визит барышында контрольдә торучы затка консультация бирә, шулай ук аның эшчәнлегенә йә аның карамагындагы контроль объектларына карата белдерелә торган белешмәләр җыя.

| № | Чара атамасы | Чараны үткәрү срогы (периодик рәвештә) | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| | **1. Мәгълүмат җиткерү** | | |
| 1.1 | «Интернет» челтәрендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында түбәндәгеләрне актуальләшү һәм урнаштыру:<br>- Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән | Даими | Җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тəэмин итү объектларын төзү, реконструкциялəү һəм (яисə) модернизациялəү буенча бердəм җылылык белəн тəэмин итүче оешма йөклəмəлəре үтəлешенə муниципаль контроль кысаларында гамəлгə ашырыла торган норматив хокукый актлар исемлеге;<br>- мəҗбүри талəплəрне үтəү буенча материаллар, мəгълүмати хатлар;<br>- мəҗбүри талəплəрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге;<br>- саклана торган зыянны (зарарны) китерү куркынычларын профилактикалау программасы. | | |
| **2. Хокук куллану практикасын гомумилəштерү** | | | |
| 2.1 | Контроль (күзəтчелек) органының хокук куллану практикасын гомумилəштерү нəтиҗəлəрен үз эченə алган хокук куллану практикасын гомумилəштерү турында доклад əзерлəү | Елына кимендə 1 тапкыр | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль һəм хезмəт күрсəтүлəр бүлеге баш белгече |
| **3. Кисəтүлəр игълан итү** | | | |
| 3.1 | Контрольдə торучы затка эшчəнлекне тормышка ашырганда мəҗбүри талəплəрне бозу очракларына юл куймау турында кисəтү бирү | Белешмəлəр булганда | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль һəм хезмəт күрсəтүлəр бүлеге баш белгече |
| **4. Консультация бирү** | | | |
| 4.1 | Контрольдə торучы затларга һəм аларның вəкиллəренə муниципаль контрольне оештыру һəм гамəлгə ашыру белəн бəйле мəсьəлəлəр буенча консультация бирү | Даими | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль һəм хезмəт күрсəтүлəр бүлеге баш белгече |
| **5. Профилактик визит** | | | |
| 5.1 | Контрольдə торучы затның эшчəнлек алып бару урыны буенча йə видеоконференция-элемтəдəн файдалану юлы белəн профилактик əңгəмə | Кирəк булган саен | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль һəм хезмəт күрсəтүлəр бүлеге баш белгече |

## 4нче бүлек. Профилактика программасының нəтиҗəлелеге һəм эффективлык күрсəткечлəре

Профилактик материалларның эффективтивлыгын һәм нәтиҗәлелеген бәяләүнең төп механизмы булып түбәндәгеләр тора:

- юридик затлар тарафыннан гамәлдәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бозу очракларының саны кимүен бәяләү;

- гражданнарның хәбәрдарлык дәрәҗәсен күтәрү;

- гражданнар һәм оешмалар белән үзара бәйләнештә, муниципаль хокукый актларны бозуларны ачыклау һәм хокук бозуларга юл куйган өчен җаваплылык чараларын оператив куллану;

- контрольдә торучы субъектларның законга буйсыну өлешен арттыруны бәяләү;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының профилактик чаралар системасы үсешенә анализ;

- профилактиканың төрле алымнарын гамәлгә кертүнең нәтиҗәлелегенә анализ;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлегенең «ачыклыгын» арттыруны бәяләү.